ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО АЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 01 2024 ел № _5__

2024 елга Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы «шәһәр тибындагы
Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 57 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитетының 2024 елның 19 гыйнварындагы «Җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясен килештерү турында»гы ЛХ-28/335/2024 санлы хатына таянып, шәһәр тибындагы Урыссу бистәсенең башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә әлеге карарның 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген 8 370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы «2023 елга

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»ндә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 4 санлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2024 елның «_26_» __01
__5__ санлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 3346,06 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1022,79 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4001,35 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2024 елның «_26__»____01____
_5___санлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә 2024 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 776,52 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 2569,54 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1022,79 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4001,35 |
| Барлыгы | 8370,20 |